Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районының «Акъяр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Акъяр авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАРЫ

2019 елның 18 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Акъяр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының 2019 елның 9 октябрендәге 60-127 номерлы "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге составына керүче торак пунктта гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" карары нигезендә, 2019 елның 18 ноябрендә Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлегендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча түбәндәге мәсьәләләр каралу турында җыенның беркетмәсе төзелде: «Сез,Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2020 нче елга, 500 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме?

Үзара салым түләүдән көндезге бүлектә укучы студентлар, Бөек Ватан сугышы ветеранының тол хатыннары, 1 нче группа инвалидлар азат ителә.Үзара салым түләүдән җыелган акчаларны Акъяр авылында түбәндәге хезмәтләр өчен кулланылачак:

- Совет урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эшләр өчен түләү);
- янгын савытын сатып алу;
- юлларны кардан чистарту;
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)
- объектларга һәм су белән тәэмин итү системасына хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт (материал сатып алу, агымдагы ремонт, өзеклекләрне бетерү, килешү буенча эш өчен түләү, шул исәптән суктыру операторына да)

«РИЗА" "КАРШЫ" "ТЫЕЛУЧЫЛАР".

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегендә барлыгы 287 граждан, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар санына 203 граждан кертелгән.
Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Риза» позициясе өчен 192 граждан тавыш бирде;
"Каршы" позициясе өчен11 граждан тавыш бирде.
"Тыелучылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Акъяр авылында халык җыены узган, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип таныргa.

2. Түбәндәге мәсьлә буенча кабул ителгән карарны танырга: «2020 елда Яңа Чишмә муниципаль районының Акъяр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 нче елга, 500 сум күләмендә үзара салым җыю белән килешәсезме?

Үзара салым түләүдән көндезге бүлектә укучы студентлар, Бөек Ватан сугышы ветеранының тол хатыннары, 1 нче группа инвалидлар азат ителә.Үзара салым түләүдән җыелган акчаларны Акъяр авылында түбәндәге хезмәтләр өчен кулланылачак:

- Совет урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, эшләр өчен түләү);
- янгын савытын сатып алу;
- юлларны кардан чистарту;
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)
- объектларга һәм су белән тәэмин итү системасына хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт (материал сатып алу, агымдагы ремонт, өзеклекләрне бетерү, килешү буенча эш өчен түләү, шул исәптән суктыру операторына да)

3. Әлеге карарны Акъяр авыл җирлегенең мәгълүмати стенды аша халыкка җиткерергә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru· урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

ТР Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге Башлыгы Д.С.Гайнуллин